# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"1998 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законына өстәмә кертү хакында

1 статья. "1998 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законының $12^1$ статьясын (Татарстан Дәүләт Советының Җыелма басмасы, 1997 ел, № 12, 1998 ел, № 8) түбәндәге эчтәлекле өченче өлеш белән тулыландырырга:

"Иректән мәхрүм итү рәвешендә җинаять җәзасын башкаручы учреждениеләрне, шулай ук Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Җәзаларны башкару идарәсе предприятиеләрен һәм оешмаларын 1998 елның 1 гыйнвареннан Татарстан Республикасының Республика бюджетына күчерелүче өлешендә өстәлгән бәягә салым түләүдән, шулай ук Татарстан Республикасында Юллар фондына, Татарстан Республикасының Экология фондына салымнардан һәм башка түләүләрдән азат итәргә".

2 статья. Әлеге законны матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 30 октябре
№ 1839